**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**ПР-179 от 24.09.2024**

**Актаныш муниципаль районының 2025 елга 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет проектын әзерләү тәртибе һәм сроклары турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184 статьясының 3 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Актаныш муниципаль районы Уставы һәм Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 27 июлендәге 16-04 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәнең 29 статьясы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләре белән берлектә, «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУ 2025 елга 2026 һәм 2027 елларның план чорына Актаныш муниципаль районы бюджеты турындагы карар проектына материаллар әзерләргә:

1) Актаныш муниципаль районының 2025 елга 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

2) Актаныш муниципаль районының 2024 елның узган чорындагы социаль-икътисадый үсешенең якынча йомгаклары һәм 2024 елда көтелә торган социаль-икътисадый үсеш йомгаклары;

3) Актаныш муниципаль районының 2025 елга 2026 һәм 2027 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы;

4) 2025 елга 2026 һәм 2027 еллар план чорына Актаныш муниципаль районының берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты) фаразы;

5) бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәпләре;

6) 31.12.2025, 31.12.2026, 31.12.2027 торышлары буенча муниципаль бурычның югары чиге турында мәгълүмат;

7) Актаныш муниципаль районы бюджетының 2024 елга көтелгән үтәлешен бәяләү;

8) Актаныш муниципаль районының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына эчке алынмалары программасы проекты;

9) 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Актаныш муниципаль районының муниципаль гарантияләре программасы проекты;

10) 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Актаныш муниципаль районының бюджет кредитлары бирү программасы проекты;

11) муниципаль программаларны 2024 елга кадәр гамәлгә ашыру срогына яңадан карарга һәм аларны алдагы срокларга раслау өчен әзерләргә.

2. 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның планлы чорына Актаныш муниципаль районы бюджеты керемнәре һәм чыгымнары фаразын билгеләү максатларында «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1) 2024 елның 10 октябренә кадәр Актаныш муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторларына - җирле үзидарә органнарына 2024 елга Актаныш муниципаль районы бюджетына алар белән идарә ителә торган керемнәр фаразы;

2) Актаныш муниципаль районы бюджетын бюджет планлаштыру субъектларына:

2024 елның 10 октябренә кадәр – 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына чыгым йөкләмәләренең беренчел реестрлары;

2024 елның 10 октябренә кадәр - 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллардагы план чорына финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән бюджет акчаларын тотуга китергән норматив хокукый актларның көчен югалткан дип тану яисә гамәлдә булуын туктатып тору турындагы тәкъдимнәр;

2024 елның 15 октябренә кадәр - 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның планлы чорына Актаныш муниципаль районы бюджеты хисабына муниципаль гарантияләр алуга беренчел гаризалар;

2024 елның 15 октябренә кадәр - 2025 елга 2026 һәм 2027 елларның план чорына Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнарының бюджет классификациясе нигезендә финанслауның иң чик күләмнәрен бүлү.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә кирәк булганда салым ставкаларын үзгәртү турында Актаныш муниципаль районы Советы карары проектын кертергә.

4. 2024 елның 20 октябренә кадәр инфраструктура үсеше буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына тәэмин итәргә:

- Актаныш муниципаль районы Советының муниципаль юл фондын төзү турындагы карары проекты;

- әйләнә-тирә мохитне саклау буенча планлаштырыла торган чыгымнарны чыгымнар төрләре буенча һәм бюджет акчаларын конкрет алучыларга бүлү.

5. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының Актаныш муниципаль районы бюджет чаралары баш бүлүчеләре булган бүлекләренә:

1) 2024 елның 10 октябренә кадәр социаль өлкә муниципаль учреждениеләренең сан үзгәрешләрен килештерергә;

2) 2024 елның 10 октябренә кадәр Татарстан Республикасының тиешле министрлыкларында һәм ведомстволарында социаль өлкә муниципаль учреждениеләре челтәре һәм контингентлары буенча сан күрсәткечләрен килештерергә;

3) муниципаль социаль өлкә учреждениеләре челтәрен арттырган очракта, Татарстан Республикасы тармак министрлыкларына һәм ведомстволарына Татарстан Республикасы башкарма органнары билгеләгән срокларда яңа муниципаль учреждениеләр ачуның максатка ярашлылыгын нигезләргә.

6. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ:

1) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән срокларда Татарстан Республикасы бюджетыннан 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план

чорына бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпләү өчен башлангыч күрсәткечләрне килештерергә;

2) 2024 елның 01 октябренә кадәр Актаныш муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына финанслауның иң чик күләмнәрен җибәрергә;

3) 2024 елның 10 октябренә кадәр Россия Федерациясе чыгымнарының бюджет классификациясе нигезендә 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына Актаныш муниципаль районы бюджетының баш бүлүчеләре тарафыннан бирелгән финанслауның иң чик күләмнәрен карарга.;

4) 2024 елның 20 октябренә кадәр «2025 елга 2026 һәм 2027 елларның планлы чорына Актаныш муниципаль районы бюджеты турында» карар проектын әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрергә.

7. 2024 елның 1 ноябренә кадәр Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына, тиешле документлар белән бергә, бюджет проектын район Советы каравына кертергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов